| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«28» май 2024 ел Алабуга шәһәре № 349

**Алабуга муниципаль Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә, Алабуга муниципаль районының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 246 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 июленнән Алабуга муниципаль Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә, Алабуга муниципаль районының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 246 номерлы карары белән расланган, Нигезләмәдә билгеләнгән, бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Алабуга муниципаль районы бюджет даирәсенең аерым оешмалары, аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазтфаи окладлары күләмнәрен арттырырга һәм түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Алабуга муниципаль районы бюджет даирәсендәге аерым оешмаларның, аларның структур бүлекчәләренең җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, аларга Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү бердәм тариф челтәре

кагылмый, торган аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләме Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаре вазифаи оклады күләмендә исәпләнә, ул 13 323 сум тәшкил итә.».

1.2. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.6. пунктының 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.11. пунктының 3 пунктчасында пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Алабуга муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетның икътисади үсеше, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов